

Рузаевка районында Татар Пешләсе дигән зур татар авылы vсеп vтыра. Еш кына бу авылда командировкада да һәм кунакта да булырга туры килә. Менә Колхозчылар дигән урамнан машина белән генә тvгел, резина калошсыз һәм итексез генә дә vтә алырлык асфальт юл тозегәннәр.Очсыз-кырайсыз кvлчекләр әле булмас һәм хатын-кызлар матур аяк киемнәреннән генә бу урам юлыннан vтәләр, бала-чага коляскада һәм велосипедта жилдертә.

Нәкъ Колхозчылар урамыннан яна Балалар бакчасына кvп кенә ата-ана vзенен балаларын озата. Бу бакчаны ачкан чакта, Республикабыз Главасы Владимир Дмитриевич Волковка, халык Колхозчылар урамы юлын тозәттерv теләге белән, морәжәгать иткән иделәр дә инде. Коткән-морадына житкән, диләр бездә. Шулай булды да: теләк тормышка ашты. Ике атна эчендә бер километр сигез йоз метр юл тозегәннәр. Асфальт юлга биш миллион сумга якын акча тvгелгән.      - Без бик тә шат бу юлга, - ди Кадрия ханым Овчинникова.- Әниебезгә шул юлдан бата-чума бара идек, ә хәзер пычрактан куркасы юк һәм ничекләр бу кvлчекләрне гизеп чыгасы дип кайгырга да кирәкми; юл ялтырап ята, укучыларыбыз да рәхәтләнеп мәктәпкә теләгән аяк киемен киеп киләчәкләр, балалар бакчасына да балаларны әти-әниләре азапланмый гына илтеп куярлар, без дә туганнарыбызга теләгән чакта тиз арада житәбез. Халык, озак котеп алган бу юл очен, рәхмәтле.

Без бит газета битләребездә бу авыл турында еш язып киләбез, халкы бик тырыш бу авылнын; Татар Пешләсе авылын горләтеп тотарга тырышалар, тозекләндерәләр. Пешлә елгасын баш-та чистарттылар, 57 машина битум валчыклары салдылар. Авыл администрациясе дә халык теләген хуплап, щебень сатып алган. Шулай әкренләп Рузаевка шәһәренә соялеп яшәгән авылны шәһәр шартларына якынайталар. Бу барысы да халык очен, киләчәк буын очен эшләнә.  Кырлы-Лугавой урамы турында да берничә сvз: vтеп булмаслык куакларны кистеләр, асфальт валчыгын юлга да сиптеләр. Зиратка юлны тозәттеләр. Менә зиратлар дигәч, Кадошкино районы Большие Поляныда Исса елгасы аркылы авыл халкынын зираты, бер урам белән икенче урамны тоташтырган кvперне Тvбән Янашәһәрдән ООО «Мостострой» бригадасы (Республикабыз

бюджетыннан дvрт миллион сум акча бvлеп бирелгән) vткәрделәр. Кvперне инде салганнарына байтак вакыт vтсә дә, халык әле дә анын аркылы vтә алмый, мәетләрне дә жирләv очен асылмалы кvпердән зур кыенлык белән кvчереп киләләр. Нишләп, дип сорарсыз; Алланын әмере белән быел янгырлар еш явып тора һәм елгада су биеклеге кvтәрелгән. Бер дә ташу вакытындагы кvк дип уйламагыз, синоптиклар урыны-урыны белән ун-унбиш сантиметргa дип хәбәрлиләр. Шул унбиш сантиметр су кvпер остеннән шаулап ага; бу кvпер булмады инде - су аркылы басма гына. Шулай булгач, бер сорау авыл халкын борчый – нинди максат белән салынды икән бу кvпер?
Шулай итеп, Большие Поляны халкынын теләге әлегә тормышка аша алмады, кvпер тозеп беткәч язылган мәкаләдә “авыл халкы теләге тормышка аша» дигән идем. Ә сикәлтәле юллары - тагы бер чишәсе башваткыч... Менә бит, Пешләлеләр булдыралар: авылларын матурлап тозекләндерәләр һәм яшәргә дә бу якларда коннән-кон унайрак була дип санарга хокуклыбыз.

**Наилә Насырова**